Бүгенге санда:



**«Халык контроле» яңа мөмкинлекләр ача. 2 бит.**


# Дуслык
Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Җомга 15 май 2015 ел

№ 35 (10564)


**16 майга һава торышы:** аязучан болытлы һава, яңгыр, җил көньяк-көнбатыштан 2-4 м/с; температура көндез +19°С, төнлә +10°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

## *Абзац-информ*

### САБАНТУЙ КӨНЕ БИЛГЕЛЕ

Нурлатта Сабантуй бәйрәме 6 июньдә булачак. Бу хакта чәршәмбе көнне район башлыгы Равил Кузюров уздырган атналык эшче киңәшмәдә әйтелде. Анда Сабантуйның кыскача планы да бәян ителде. Быел милли бәйрәмне үткәргәндә, театрлаштырылган һәм спорт мәйданчыкларының урыннарына кагылышлы үзгәрешләр дә булачак икән.

### АВЫЛ КЕШЕЛӘРЕ ФЛЮОРОГРАФИЯ ҮТӘ

Кичәгедән күчмә флюорографик җайланма эшли башлады, ул 8000 авыл кешесен колачлаячак. Флюорографик җайланма шулай ук шәһәрнең эре предприятиеләрендә дә эшләр, дип планлаштырыла.

### БАШЛАНА...

Бу атнада районның 578 IX сыйныф укучысы татар теленнән Бердәм республика тестлаштыруы узды. Ә 25 майдан XI сыйныфлар өчен география һәм рус әдәбиятыннан Бердәм Дәүләт имтиханнары башлана.

### МӘКТӘБЕБЕЗГӘ БУЛЫШЫЙК!

Районда 2015/2016 уку елына әзерлек эшләре – "Үз мәктәбеңә булыш" республика акциясе старт алды. Узган уку елында әлеге чара кысаларында районның белем бирү учреждениеләренә 1 миллион сумлык ярдәм күрсәтелгән булган.

### БАЛАЛАР КОРЪӘН УКЫЙ

Бу якшәмбедә шикәрчеләр бистәсе мәчетендә 15 яшькә кадәрге балалар арасында традицион Коръән уку бәйгесе уза. Чара сәгать 9да башлана.

### ӘЗЕРЛЕК ТИКШЕРЕЛӘ

Мәктәп укучылары арасында "Хезмәт һәм оборонага әзер бул!" бердәм декадасы 25 майга кадәр барачак. Әлеге чара кысаларында бу көннәрдә район мәктәпләрендә сыйныф сәгатьләре, спорт – сәламәтләндерү чаралары уза.

# Үсешкә йөз тотып




ТАШЧЫЛАР ВЛАДИМИР БУЛАТОВ, АЛЕКСЕЙ МАЙОРОВ ҺӘМ СЕРГЕЙ ЯЛЛИН ЭШТӘ

**2014 ел нәтиҗәләре буенча Татарстан бишенче ел рәттән төбәк башкарма хакимиятләре органнарының эшчәнлек нәтиҗәлелеге җәһәтеннән беренче урын алды. Әлеге рейтингның нәтиҗәләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 7 майда узган утырышында яңгырады.**

Татарстан югары күрсәткечләрне саклап кына калмый, ә барлык социаль-икътисади юнәлешләр буенча үсеш темпын раслап та тора. Соңгы биш елда республикабыз мөһим социаль-икътисади күрсәткечләр буенча лидерлык позициясен ныгытты, биредә эре инновацион проектлар да үсештә. Әлбәттә, республиканың гомуми уңышында нурлатлыларның өлеше дә бар. Район җитәкчелегенең социаль-икътисади үсеш уңаеннан колачлаган курсы гына да ни тора. Шәһәр һәм район инфраструктурасы үсешенә бирелгән темп Республика лидеры Рөстәм Миннеханов стратегиясенең чагылышы да, һәм ул Татарстанның тотрыклылыгын, үсешен тәэмин итә.

Бу көннәрдә шәһәрнең стратегик объектларының берсендә тулы көченә төзелеш эшләре бара. Төньяк-Көнчыгыш микрорайонда төзелүче 260 урынлы балалар бакчасын нәкъ шулай атап була да, чөнки биредә асылда яшь гаиләләр яши, ә янәшәдә күп балалы гаиләләргә җир участоклары бүлеп бирелгән. Яңа уку елыннан бакча эшли башлаячак. Шуңа да бүген биредә эшләр кызу темплар белән бара. Төзелеш гыйнварда башланган иде, ә бу вакытка цоколь һәм беренче катлар төзелгән, икенче катны кору эшләре дәвам итә.

– Кайбер эшләрне параллель алып барабыз, – ди "ПИК+" подряд оешмасы директоры Марат Саттаров, ул объектка Казаннан атнасына 2-3әр тапкыр килеп китә. – Хәзер тышкы челтәрләрне: сүүткәргечен, канализация, газ сузу эшләрен башладык. Киләсе атнада блоклы котельняны корачакбыз, шулай ук территорияне төзекләндерүгә алынырга планлаштырабыз.

Бүгенге көндә биредә 30 кешедән торган 2 ташчылар бригадасы мәшгуль, краннар, "КамАЗ"лар, экскаватор, төягеч җәлеп ителгән. Ә ике атнадан соң, Марат Саттаров әйтүенчә, фасадны тышлауга керешәчәкләр. Июньдә электр үткәрү һәм эчке отделка белән шөгыльләнмәкчеләр, ә августта объектны тапшырырга ниятләп торалар.

Шәһәрнең икенче почмагында "НурлатЕвроСтрой" подряд оешмасы көче белән зур реконструкциядән соң Халыклар Дуслыгы йорты ачылачак. Күп еллар дәвамында буш торган әлеге бина бер ел эчендә матур архитектур төс алды. Халыклар Дуслыгы йорты, мәдәни-агарту эшчәнлегеннән тыш, этникара татулык һәм дуслык хакына иң мөһим функцияләрнең берсен дә башкарачак. Әле кайчан гына шәһәрлеләр тагы бер мөһим социаль объект – бик тә тәҗел һәм күптән көтелгән муниципаль мунчаны ачу тантанасында катнаштылар. Ә бүгенге көндә капиталь ремонт алып барылучы объектлар күпме? Һәм бу күпфатирлы йортлар гына түгел әле. Мисал өчен, "Энергострой+" бу көннәрдә Нурлаттагы дәүләт ветеринария берләшмәсе бинасын капиталь ремонтлауны дәвам итә, ә "ГородСтрой" Каравыл Тавындагы күпфункцияле үзәк бинасын төзү белән мәшгуль. Яңа уку елында шәһәрнең 2нче, Фома, Колбай Мораса мәктәпләре укучыларны капиталь ремонттан соң кабул итәчәк...

Узган елда нурлатлыларны күләмле юл эшләре сөендергән иде, быел исә "Главтатдортранс" ДКУсы линиясе буенча гына да район һәм шәһәрдә юллар ремонтлау һәм төзүгә 200 млн. сумнан артыграк акча бүлеп бирелгән, "Татнефть" ярдәме белән тагын 50 млн.лык юл эшләре башкарылачак, җирле муниципаль юл фондыннан 17 млн. тотылачак. Боларның барысы да районыбыз социаль-икътисади үсешенең колачы күрсәткече.

Сирень САМӘРХАНОВА


ООО «Вектор - Навигатор» 106 167 700 1935 гос.рег.номер

8 800 700 79 51



ВЕКТОР НАВИГАТОР

ТАХОГРАФЫ

Реклама

УСТАНОВКА | ОБСЛУЖИВАНИЕ | КАРТЫ ВОДИТЕЛЯ: ИЗГОТОВЛЕНИЕ И РАЗБЛОКИРОВКА

Казань: 8 967 460 71 74 ■ Чистополь: 8 967 460 71 73


## *"ДУСЛЫК"ка ТАШЛАМАЛЫ БӘЯДӘН ЯЗЫЛЫГЫЗ!*

**14-23 майда "Дуслык" район газетасына ташламалы бәяләрдән – почта адресына 486 сум 72 тиеннән, альтернатив газетага 270 сумнан язылырга ашыгыгыз! Күмәк язылырга теләүчеләрне урынга чыгып яздырабыз. Тел: 2-36-12.**

# КӨН АРТЫННАН КӨН

ДЕПУТАТ ХОЗУРЫНДА

## ЯРДӘМНЕҢ ЧИГЕ ЮК

**Нурлат сайлаучылары чираттагы тапкыр үз проблемаларын Татарстанның Дәүләт Советы депутаты Илгиз Салихов белән уртаклаша алдылар.**

Мөрәҗәгать итүчеләр арасында Фома авылыннан килүче дә бар иде.

– Юл сала башладык, ярдәм булмасмы дигән идек, - диде Рамил Газизов. Моңа Илгиз Салихов "Татнефть" линиясе буенча район юлларын ремонтлауга 50 миллион сум бүлеп бирелүен әйтте. Бу суммага, бәлки, аларның авылы да кертелер.

Торак проблемасы – нурлатлылар депутатка мөрәҗәгать итә торган мәсьәләләрнең берсе. Илгиз Салихов шәһәрдә яшәүче өлкән яшьтәге ханымның проблемасын өйрәнергә ышандырды. Эш шунда, Вера Маркеловнага үз вакытында фатир алу һәм аны хосусыйлаштыру өчен бик күп чиновникларның бусагасын таптарга туры килгән. Вакытлар узу белән гаилә советында бу фатирны сатарга карар итәләр, ә пенсионер ханым кызына күченә. Бар да яхшы булыр иде дә, тик кызы үлеп китә...

Бөек Ватан сугышы толы Әнисә Абдрахманованың Дәүләт Советы депутаты янына беренче генә килүе түгел. Элекке тапкырында ул участогына туфрак, я булмаса ком китерүләрен сораган иде.

- Рәхмәт, икенче көнне үк китерделәр, - дип сүзен рәхмәттән башлады ул. Бу юлы исә гаилә проблемасы борчый икән үзен. Тик Әнисә Әхмәдиевна өчен чишелмәслек булып тоелган проблеманы депутат бик тиз хәл итте. Кызганычка каршы, гаиләдәге аңлашылмаучанлыклар еш кына буыннар арасында упкыннар хасил итә шул.

Михаил Андриянов кабул итүгә Аксубай районыннан ук килгән, әмма аны да кире бормадылар. Эш шунда, Михаил Сергеевич 30 еллап нефть һәм газ предприятиесендә эшләгән. Бу көнне исә йортын ремонтларга булышуларын сорады.

– Ветеран үзебезнеке. Булышырбыз, – диде Илгиз Салихов.

Бу юлы депутатка территорияне төзекләндерү, күпфатирлы йортка капиталь ремонт ясау белән бәйле сораулар белән дә килгәннәр иде. Кемдер консультация алды. 12 мөрәҗәгатьнең берсе дә игътибарсыз калмады.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

ЯЗГЫ ЧӘЧҮ



ИГОРЬ СЕМИБРАТОВ ҺӘМ ФАИЛ КАМАЛЕТДИНОВ БАСУДА

## Нурлат шикәрле булачак

Быел районда шикәр чөгендере 6400 гектарда игелә. Төп мәйданнар исә "АгроИнвест" идарәче компаниясенә караган "Сөләйманов Ә.И" һәм "Южная" хуҗалыкларына туры килә. Шул көннәрдә алар татлы тамыр чәчүне тәгәлләделәр.

"Сөләйманов Ә.И" крестьян-фермер хуҗалыгында шикәр чөгендере 3350 гектарда быел. Хуҗалыкның тырыш механизаторлары Фаил Камалетдинов белән Игорь Семибратов шикәр чөгендере чәчүдә мәшгуль булдылар. Гомумән, татлы тамырны 4 заманча агрегат белән кыска срокларда чәчеп өлгерделәр хуҗалыкта. Бу көннәрдә инде шыткан үсентеләрне махсус препаратлар белән авырулар һәм корткычларга каршы эшкәртә дә башладылар.

"Туфракка күмдергән белән генә түгел, чәчкәнне саклап үстерергә дә кирәк әле. Шикәр чөгендере кебек нәзберек культура турында сүз барганда – бигрәк тә", - диләр хуҗалыкта һәм быел да чөгендер игүнең барлык таләпләрен истә тотып, мул уңыш алырга исәплиләр

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

САН

**Кичәге көнгә район буенча бөртеклеләр чәчү 21367 гектарда, барлык мәйданнарның 92 процентында тәгәлләнде.**

ЮЛЛАРДА

## ИСЕРЕКЛӘРГӘ АКЫЛ КЕРМИ

**Бәйрәм көннәрендә район юлларында аек булмаган көе руль артына утырган 5 кеше тоткарланган. ЮХИДИ мәгълүматларыннан күренгәнчә, исерек килеш руль артына ир-атлар гына түгел, хатын-кызлар һәм өлкән яшьтәгеләр дә утыра икән.**

Бәйрәмнәр алдыннан ЮХИДИ хезмәткәрләренең рейды вакытында салган көе руль артына утырган хатын-кызны тоткарлыйлар. Әмма руль артындагы ханым экспертиза үтәргә теләми. Тик аңа барыбер суд каршына басарга туры киләчәк. Икенче бер – 83 яшьлек машина йөртүче дә Җиңү көнен 6 майдан ук бәйрәм итә башлаган, күрәсең. Исерек көе машина белән идарә иткән әлеге ир-ат үз көченә генә ышанып бетмиме – соңрак рульне исерек дустына тапшыра. Шул рәвешле, ул законны икеләтә боза...

Инспекторлар әйтүенчә, суд тарафыннан машина йөртүче таныклыгыннан мәхрүм ителгән кешеләр,аны ЮХИДИ бүлегенә тапшырырга ашыкмыйлар, ди. Бүлектә әйтүләренчә, документ тапшырылган сроктан башлап кына карар үз көченә керә икән. ЮХИДИ хезмәткәрләренең тагын бер проблемасы –штрафларны вакытында түләмәүчеләр. Районда 5 кешенең 50шәр мең сумнан артык штрафлары түләнмәгән. Шуларның берсе бурычлы көе үлеп тә киткән инде.

– Ел башыннан гына да 120 кеше штрафларын вакытында түләмәгән өчен җаваплылыкка тартылды, - ди ЮХИДИ бүлеге начальнигы Рөстәм Гарипов. – Шуларның 57сенә административ арест салынса, 55енә штрафны икеләтә суммада түләргә туры килде.

Штрафларын 60 көн эчендә түләмәүчеләр арасында бер предприятиенең вазифаи заты – урта звено начальнигының штрафы 5 мең сумнан артып киткән була. Чираттагы рейд вакытында инспекторлар әлеге затны юл хәрәкәте кагыйдәләре бозган өчен тоткарлыйлар. Әмма кагыйдә бозучы инспекторларны санга сукмыйча качып китә. Суд кагыйдә бозучыны 30 сәгать мәҗбүри хезмәткә тарту турында җәза чыгара. Якын араларда исә җәзалар тагы да кырысланачак. Мисал өчен, эчкән килеш руль артына утырган машина йөртүче кабат инспекторлар күзәтүенә эләгеп, медицина тикшерүе үтүдән баш тартса, җинаять җаваплылыгына тартылачак. Әлеге закон 2015 елның 1 июленнән гамәлгә керә. Бу төр хокук бозган өчен 200 мең сум күләмендәге штрафтан алып ике елга кадәр иректән мәхрүм итү каралган. Исерүгә китергән сәбәпләр дә (исерткеч эчемлекләр, наркотик яки психотроплы матдәләр) ачыкланырга тиеш. Кеше үлеменә китерүче һәлакәтнең сәбәпчесе булган исерек машина йөртүчеләргә карата да җәзалар үзгәрә. Законга кертелгән яңа өстәмәләр нигезендә, юл-транспорт һәлакәтендә бер кеше үлгән очракта – 2 елдан 7 елга кадәр, 2 һәм аннан да күбрәк кешенең гомере өзелгәндә, 4 елдан 9 елга кадәр иректән мәхрүм итү каралган.

**Зилия ӘКСАНОВА**

15 МАЙ – ХАЛЫКАРА ГАИЛӘ КӨНЕ

## Гомергә бергә...

**Иске Әлмәт авылында яшәүче Рәшит һәм Разия Гатиннарның бергә яшәүләренә 67 ел була. Гатиннарның үз гаилә традицияләре, үз йолалары бар.**

Ишле нәсел бергә җыелганда, алар өч дистәдән артып китәләр. Әнә, гаилә башлыгы, әтиләре, бабалары Рәшит аганың 90 яшьлек олы юбилеен да Казанда "Туган авылым" күңел ачу комплексында зурлап, гаилә бәйрәме итеп үткәргәннәр.

Халыкара гаилә бәйрәме алдыннан гына гаилә башлыгы Рәшит ага Гатин юбилее уңаеннан РФ Президенты Владимир Путин һәм район башлыгы Равил Кузюровның котлауларын кабул итте. Ветеранны олы юбилее белән район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова котлады.

Иске Әлмәт авылы егете Рәшит Гатин фронтка 1943 елда алына. 16нчы Кызыл Йолдыз орденлы танк бригадасының Икенче, Өченче Балтыйк буе фронтлары частьләрендә сугыша. Эстония, Латвия, Литваны азат итүдә катнаша, батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә. 1945 елда Берлин янында барган сугышларда каты яралана. Германия, Украинаның Житомир шәһәрендә госпитальләрдә дәвалана һәм июль аенда демобилизацияләнеп туган ягына кайтып төпләнә. Колхозда баш бухгалтер, ревизия комиссиясе рәисе булып эшли. Аннан төрле эшләрдә була.

23 яшендә авылның иң матур



ГАТИННАР – ИСКЕ ӘЛМӘТНЕҢ ИҢ ХӨРМӘТЛЕ ГАИЛӘЛӘРЕННӘН

кызларыннан берсе Разия белән гаилә корып җибәрәләр, 8 балага гомер бирәләр. Кызганыч, бүген балаларының 3се вафат инде. 9 оныклары, 15 оныкчыкларына шөкерана итеп яшиләр Гатиннар. Ә менә 67 ел матур, тату итеп яшәү серен алар сабырлыкта, диләр.

- Иң мөһиме – бер-береңә юл бирә белергә кирәк, - ди Рәшит Шаһитович. – Хөрмәт булганда, бер-береңне тыңлый белгәндә, гаиләдә низаг чыкмый ул.

Озын гомерле булулары исә нәселдән дә киләдер, мөгаен.

- Әтием 90га кадәр яшәде, - ди Рәшит ага. – Аннан, сәламәт яшәү рәвеше алып баруның да йогынтысы юк түгелдер.


Разия апа төп йортка килен булып төшкәч тә 30 ел каената-каенана белән яши. Алар мәрхүм булгач, Разия апанаң үз әнисен яннарына алалар.

– Иптәшем сабыр холыклы, уйлап эш итә торган кеше булды, - ди Разия апа бүгенге тормышына шөкерана итеп. – Ә хезмәтебез беребезнеке дә җиңелләрдән булмады. Өстәвенә, йорт, бакча мәшәкатьләре. Шөкер, хәзер балаларыбызның кадер-хөрмәтендә яшибез. Алар Казан, Түбән Кама, Чистай, Нурлат шәһәрләрендә яшәсәләр дә, һәрвакыт кайтып торалар. Кышын алар янына барабыз. Иң мөһиме, Ходай сәламәтлектән аермасын да, илдән аерым кайгылар бирмәсен, диләр Рәшит ага һәм Разия апа Гатиннар.

**Зилия ӘКСАНОВА**

ХАТЛАР КИЛДЕ...

# Әткәй әле дә янәшәдә сыман



...1973 ел. Безнең Зирекле авылында көтүләр соң чыга. Шуңа да һәр ел саен юллар төшүгә, май башында яшь терлекне Берлеккә – туган абыйларга илтә идек. Ә анда урманда көтүләр бик иртә чыга, көзгә хәтле иректә азыкта була иде малкайлар.

Әти арбада, ә мин акрын гына тананы куа барам. Азрак баргач, Чирмешән күперен чыгабыз, танабыз да җайлана, үз көенә арба артыннан бара бирә. Караңгы төшә башлый. Берчак әти тәмәке кабызды. Әтинең тәмәке тартканын күргәнем юк иде. Гаҗәпләндем, күрәсең, ә этием аклан-ган сыман: "Кызым, мин болай гына, урманда утсыз булмый," – дип куйды. Ә аннан соң җыр сузып җибәрде. Әткәй матур җырлый, мәҗлесләрдә табын күрке була торган иде. Мин тыныч кына тыңлап барам. "Гөлҗамал", "Кара урман", "Нигә синең шаян күзләр"не сузды, ә аннары русча җыр башлады:

"У незнакомого поселка,
На безымянной высоте..."

Миңа аның русча җырлавы гаҗәп тоелды. Түзмәдем, "Әти, ник русча җырлыйсың?" – дип сорадым.

– Утыр арбага, хәзер тана ат артыннан үзе дә бара, – дип, әти хатирәләрен барлый башлады. Бөтенесен төгәл яза алмасам да, күп нәрсә истә әле.

Әтием, Гариф Нурулла улы, заманына күрә алдынгы карашлы, төпле фикерле, белемле кеше була. Фома 7 еллык мәктәбен, Кизләү урта мәктәбен тәмамлый, башлангыч мәктәптә укытучы булып эшли. 1938 елда совет армиясе сафларына алынып, 1944 елның мартына кадәр Ватан өчен сугышларда катнаша. Хәрби кадрлар әзерләү курсын үткәч, 1942 елда ул ут эченә керә. 1943 елның августында командирларга хәрби задание бирелә: "Сугышчы яралымы-юкмы, ул аягында йөри, кулына мылтык тота ала икән, атакага күтәрелергә, билгеләнгән биеклекне алырга. Бурычны үтәп, исән калсагыз, сез хөкүмәтнең иң югары бүләгенә лаек булачаксыз". Әтием белән бер татар кешесе дә була. Күп югалтулар бәрабәренә биеклек алына. Яралыларны, һәлак булганнарны барлаганда, әтинең үле гәүдәсе табылмый.

- Ул исән булырга тиеш,– ди якташы. Эзли торгач, иптәшләре әтине табып алалар: снаряд шартлап, аны җир белән күмгән, ә чәчләре ап-акка әйләнгән була. Яралы хәлдә аны госпитальгә озаталар. Госпитальдан чыккач, лейтенант Сәлимов запаска җибәрелә.

Ә батырлыклары өчен әтием СССР Верховный Советы Президиумының 1945 елгы 4 май указы белән II дәрәҗә Ватан сугышы орденына тәкъдим ителә. Тик бүләк хуҗасын 20 ел үткәч кенә эзләп таба. Ул бүләкне әтиебезгә 1966 елда тапшыралар. Бу хакта район газетасында "20 елдан соң орден хуҗасын тапты" дигән мәкалә дә басылып чыккан иде. Ә I дәрәҗә Ватан сугышы орденын әтигә 1985 елда тапшыралар.

Сугыштан соң әтием төрле тармакларда эшли. Военрук, Фома авыл советы рәисе, 1954-1958 елларда КПСС райкомының Чулпан МТСы буенча партия инструкторы, Госстрах хезмәткәре булып гомер буена намуслы хезмәт куя. Кайда гына булмасын, нинди генә эштә эшләмәсен, аның турында: "Ачык йөзле, кешелекле, туры сүзле, итагатьле кеше иде", – дип сөйлиләр. 37 ел мәктәптә әтиемне белгән, аны күргән кешеләр белән эшләгәндә, аның турында бары тик җылы сүзләр генә ишетеп горурландым. Холкым белән, күңелем белән мин һаман әткәй кызы.

Рәзинә СӘЛАХОВА, Фома авылы

## ҖИҢҮ КӨНЕНӘ - АКЦИЯ

Илебез Бөек Җиңүнең 70 еллык олы юбилеен билгеләп үткән көннәрдә, без мәктәбебездә "Ветераннар янәшәдә!" акциясе оештырдык. Аның барышында ветераннар, тыл хезмәтчәннәре, сугыш чоры балалары белән очрашып, видеоязмалар төшерүне, истәлек ядкәрләр язып алуны максат итеп куйдык. Сугыш башланганда, Фәрбизә әби Гафиятуллинага биш яшь кенә булса да, әтисен сугышка озатып калганын, әнисе белән бергәләп әтисеннән килгән хатларны укыганнарын, тылдагы авыр тормышта яшәүләрен бик яхшы хәтерли... Фәрбизә әби бүген туганнары Вәгыйзь һәм Суфия Гыйззәтуллиннар гаиләсендә гомер итә.

Энҗе МИНГАЛИМОВА, Киекле мәктәбе

## МӘҢГЕ СҮНМӘС ХӘТЕР

Миннәхмәт бабам белән Нурбисал әбием тыныч кына гомер кичереп, балалар үстереп ятканда, Бөек Ватан сугышы башлана. Минәхмәт бабам сугышның беренче көннәреннән үк фронтка китә. Аңа бу вакытта 33 яшь була. Ерак әбиемнең әнисе гомеренең соңгы көненә кадәр иренең ничек сугышка киткәнен сөйли торган булган. "Безнең өй каршысында багана башында радио бар иде. Бөтен авылдашлар шул радио янына җыелдылар. Районнан килгән кеше бөтен ирләрне сугышка, Ватанны сакларга чакырды, сугышка китүчеләрнең исемнәрен укып чыкты", – дип искә ала иде ул. Бу исемлектә минем дә дәү бабам булган. Бабам үзенең капчыгына кирәк-яракларын тутырып, карт әбиемне, берсе – 5, икенчесе 3 яшьлек кызларын кысып кочаклаган да саубуллашып, сугышка киткән. Яулык чите белән авызын томалап, тавышсыз гына елап калган карт әбием бабамны соңгы тапкыр күрүен аңламагандыр да әле ул чакта.

Бабам авыр яраланып госпитальгә эләгә. Аннан терелеп чыккач, ул үз теләге белән кабат сугышка китә. Аның белән бергә булган бер авылдашы: "Бу бәрелешкә кергәндә, Миннәхмәт бик каушады. Әгәр исән калмасам, бәхил булыгыз", - дип әйтте, дигән соңгы хәбәрне җиткергән.

Сугыш кырындагы хәбәрләрне тылда яшәүчеләр хатлар аша беләләр. Ай, ул кош теледәй солдат хатлары! Күпме кеше тилмереп көткән аларны. Сугыштан бабамның да берничә хаты килгән. Бер хатында ул болай дип язган: "Исәнме, Нурбисал һәм матур кызларым. Әлегә исән-саумын. Фашистларны куып алга барабыз. Бераз гына түзегез. Сугыш озакламый бетәчәк. Сагынуым шулкадәр көчле. Тик күрешә алырбызмы – аны-сын белмим. Кызларны сакла. Сәлам белән, сезне сагынып Миннәхмәт". Бу – бабамның соңгы хаты була. Без аны әле дә саклыйбыз. Сугыштан да рәхимсезрәк нәрсә бар бу дөньяда? Кара мөһерле кош теледәй кәгазь кисәге бәгырьләрен өзеп, минем карт әбиемне дә канлы яшь түктергән. Минәхмәт бабам сугышта хәбәрсез югала. Ә карт әбием гомере буе яраткан иренә тугры кала. Гомеренең соңгы көненә кадәр көткән бабамны, бәлкем, бер кайтыр, дип өмет иткәндер инде. 1990нчы елда бабамның Көнбатыш фронтта һәлак булуы һәм каберенең табылуы турында хәбәр килгән. Тик әбиемә бу хәбәрне ишетергә насыйп булмады: 38 ел ирен көткәннән соң ул вафат булды.

Ләйлә ӘХМӘТОВА, Кизләү мәктәбе

## ҮТЕМЛЕ ТӘРБИЯ ЧАРАСЫ

1960-70 елларда миңа Кизләү урта мәктәбендә Бөек Ватан сугышыннан Җиңү яулап кайткан авылдашларым белән эшләргә туры килде. Гыйльман Камалов, Ислам Туешов, Габбас Гыймалетдинов, Мирза Галимов, Салих Усманов, Шәйхетдин Йосыпов, Җәмил Кәримов. Кызганыч, алда телгә алган ветераннарның берсе дә исән түгел инде, әмма аларның фидакарь хезмәтләре онытылмый. Мисал өчен, гвардия лейтенанты Гыйльман Камалов танк командиры буларак Берлинны штурмлау операциясендә катнашкан. Алар укучылар белән бик еш очрашулар үткәрә иделәр. Бу тәрбияви яктан зур роль уйнады. Ветераннарның үтемле сүзләренең яшь буынны хәрби-патриотик яктан тәрбияләүдә һичшиксез әһәмияте зур. Әнә, Кизләү урта мәктәбен тәмамлаган укучылар армия хезмәтен зур горурлык белән үтеп килделәр. Араларында югары хәрби дәрәҗәгә ирешүчеләр дә байтак. Мәктәп чыгарылышлары Әнәс Мортазин, Роберт Яруллин, Владимир Куликов – полковник, Иван Никифоров, Анатолий Кораблев, Петр Антонов, Рафикъ Кәлимуллин, Андрей Жуков, Илшат Бәхтияров, Нургали Дәүләтшин подполковник дәрәҗәләренә кадәр күтәрелделәр.

Ислам БӘХТИЯРОВ, Нурлат

## ӘТИЕМНЕ САГЫНАМ

9 май бәйрәмендә күңелләрдә хатирәләр яңара. Әтием Насыйбулла сугыштан 21 яшендә яраланып кайта. Күзе һәм кулы мина ярчыгыннан зыян күрсә дә, әтием үзен инвалидка санамады, томышны бик яратты, һәр нәрсәдә матурлык, яхшылык күрә белде. Әнием Миннегөл белән 1949 елда гаилә корып, 6 балага тормыш бирәләр, бүген аларның 3се генә исән. Әтием үзен сукыр, бармаксыз, дип төшенкелеккә бирелеп утырмады: туган авылы Савинда озак еллар колхозда төрле эшләрдә хезмәт куйды. Киң күңелле, ачык йөзле әтием театрда да уйнаган, уң кулында исән калган ике бармагы белән гармунда өздереп уйнап җырлавын әле дә онытмыйм. Әтием безгә сугыш турында сөйләргә бик яратмый иде. "Сугышның бер кызык җире дә юк, үскәч белерсез әле", – дия иде. Әтиемнең вафатына 30 еллап гомер узса да, мин аны еллар узган саен ныграк сагынам.

Наилә НАСЫЙБУЛЛИНА, Чулпан авылы

## ХӘБӘРСЕЗ ЮГАЛГАН АБЫЕБЫЗ

Бу тормышта беркем дә, бернәрсә дә онытылмый, диләр. Әмма, кызганычка каршы, Якты Күл авылы егете Зәйдулла абыебыз турында 70 елдан артык инде бер хәбәр дә белмибез.

Әнием Минҗиян Шәрипованың энесе Зәйдулла абыем 1913 елда туган. Димитровград шәһәрендә укытучылар институтын тәмамлап кайткач, Түбән Нурлат авылы мәктәбенә эшкә урнаша. Шул вакытта Зиннәт исемле сөйкемле кыз белән танышып, гаилә коралар, Гөлсәрия исемле кызлары туа. 1939-40 елларда абыемны армия хезмәтенә алалар, шунда үзен политрук итеп куялар. Хезмәттән яраланып кайтса да, Бөек Ватан сугышына озатыла һәм октябрь аенда ул һәлак була. Кызганыч, сугыш тәмамлануга 70 ел гомер узса да, якын кешебезнең кайда җирләнүе турында бер архивта да мәгълүмат юк. Безнең кулда аның 1942 елның октябрендә хәбәрсез югалуы һәм һәлак булуы турындагы язу гына бар. Абыебызның кайда күмелүе турында берни белмибез. Мәргүбә әбиебез һәм Вәлиулла бабабызның 4 кызы арасында бердәнбер уллары булган ул. Ә төпчек кызы Галиясенә этисен күрергә насыйп булмады. Бүген кызлары һәм оныклары, туганнары өчен Зәйдулла абыебызның сугыштан язган хатлары, җырлары гына кадерле истәлек булып саклана.

Фәүзия ШӘРИПОВА, Чаллы Башы авылы

## БАБАМНЫҢ ДА ӨЛЕШЕ ЗУР

Бөек Җиңүгә минем бабам Миркәй Гомәров та үз өлешен керткән. Бабам вафат булганнан соң гына тусам да, мин Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераны оныгы булуым белән горурланам, бабам турында шактый истәлекләр беләм. 14 яшеннән әнисез үскән Миркәй бабамны тормыш төрле яклап сыный. Әнисе вафатыннан соң, бабам Мәскәүгә китә һәм 1941 елның 1 августында сугышка алына. 30 августта 7нче танк бригадасы составында шофер булып сугышка керә. Һәм шул взводта 1944 елның 16 сентябренә кадәр сугышкан. Симферополь янында барган сугышларда каты яралана, башына пуля эләгә. Сугыштан соң да ул 50 ел сугыш ярасы белән яшәгән. Бабам оста тегүче дә, балта остасы да булган. Сугыштан кайткач, әбием Минҗиһан белән гаилә корып, 6 баланы олы тормыш юлына бастырганнар. Бабамның вафатына да 22 ел гомер узган инде хәзер. Һәр ел саен әти-әнием белән бергә бабамны кадерләп искә алабыз, каберен зыярәт кылабыз.

Дилүс ШӘКҮРОВ, Нурлат

ПРОБЛЕМА

# Соры хезмәт хакы алу – үзеңнекен урлау ул

**Анна вуз тәмамлаганнан соң, биш ел буе бер шәхси оешмада эшли. Аңа барысы да ошый: яхшы хезмәт хакы, чит илдә ял, машина. Әмма декрет ялына чыгар вакыт җиткәч, аның моңа хакы юк икәнлеге ачыклана. Һәм бу бердәнбер очрак түгел, ә җәмгыятебездәге зур проблеманың асылы.**

## ОТПУСК ТА, ДЕКРЕТ ТА ЮК

Нәрсә соң ул “соры” хезмәт хакы? Авырсаң, хастаханә кәгазе ала алмыйсың, түләүле отпуск та, күчемсез милек сатып алганда яки баланы укытуга социаль түләүләр дә юк. Һәм бу тормыштагы башка тармакларга да зарар сала. Бюджет салым түләүләре белән тулыланмый. Ә монысы социаль әһәмияттәге мәсьәләләр хәл иткәндә үзен сиздерәчәк. Эшкә рәсми булмаган рәвештә урнашу киләчәктә пенсия түләүләрендә дә чагылыш табачак. Бу хакта 12нче районара салым инспекциясе баш инспекторы Ләйсән Мөлекова җиткерде. Статистика буенча, “рәсми булмаган” хезмәт базары сатучылар, шәхси оешмаларда еш чагыла, эшмәкәрләр хезмәт килешүләре төзеп тормыйлар яки мәгълүматларда хезмәт хакын азайтып күрсәтәләр. Ел башыннан Россиядә минималь хезмәт хакы күләме үсте: хәзер ул аена 5965 сум тәшкил итә. Ә республикада узган ел төзелгән килешү буенча, икътисадның бюджеттан тыш секторына караган оешмаларда ул кимендә 6420 сум. Шул рәвешле, һәр хезмәткәр, тулы ай эшләгән очракта, әлеге суммадан да аз хезмәт хакы алмаска тиеш.

## ПЕНСИЯСЕЗ КАЛУЫҢ ИХТИМАЛ

– Быелдан яңа пенсия формуласы гамәлгә керде, әгәр дә гражданнар Пенсия фондына түләүләр күчермәсә, аларның пенсияләре минималь булачак, – ди Пенсия фондының Нурлат районы һәм шәһәре идарәсе начальнигы Рушания Шакирова. – Чөнки баллар суммасы легаль стажның озынлыгына һәм рәсми хезмәт хакының күләменә бәйле: ул күбрәк булган саен, пенсия дә зуррак булачак.

Димәк, “соры” хезмәт хакын юкка чыгару ике яклап отышлы: район бюджетының тулылануы һәм яхшы лаеклы ял турында кайгырту. Шуңа да эшкә законлы итеп урнашу дәүләт өчен генә отышлы, дип уйлаучылар нык ялгыша.

## ЗАКОН БОЗГАНГА ҖӘЗА БАР

Эш бирүчеләргә хезмәт законнарын бозган өчен җаваплылык чаралары да көчәйтелде. Хезмәт хакын минималкадан азрак түләгән өчен кисәтү бирелергә яисә вазифаи затларга 1-5 мең, юридикларга 30-50 мең сумга кадәр административ штраф салынырга мөмкин. Законны кабат бозган очракта, штрафлар суммасы арта. Хезмәт килешүе төзүдән баш тарту яки аны тиешенчә төземәү вазифаи затларга 10-20 мең, юридикларга 50-100 мең сумлык штраф белән яный. Бу закон кабаттан бозылса, эшкә урнашучылар үзләре дә җавап тотачак, аларга 5 мең сум штраф салына. Ә вазифаи затлар 1-3 елга кадәр бөтенләй дә дисквалификациягә дучар ителә. Юридик затлар 100-200 мең сум түләргә мәҗбүр булачаклар. “Тәбедәге бушлай сыр”, ягъни эшмәкәрләрнең хезмәткәрләре хисабына баеп китәргә омтылуы, хезмәт законнарын үтәмәве өчен әнә шулай түлисе була.

## ӨСТӘМӘ КИЛЕШҮЛӘР ИМЗАЛАНА

“Соры” хезмәт хаклары белән проблеманы хәл итү өчен эшмәкәрләр һәм предприятие җитәкчеләренә һәр хезмәткәргә аерым килешү төзеп китерергә тәкъдим ителде, ул барлык күчерелергә тиешле түләүләр гаранты булып торачак. Территориаль үсеш бүлегеннән әйтүләренчә, бүгенге көнгә 1386 өстәмә килешү китерелгән.

– Бүгенге көнгә өстәмә килешүләр кабул итү планы 75 процентка үтәлде, – дип билгеләп үтә район башкарма комитетының яшәү дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне гальләштерү буенча ве... ствоара комиссия рәисе Ру... Морадыймов. – Бу эшмәка... һәм предприятиеләрнең ... тивлыгын раслый. Хезмә... куклары бозылса, хезм... Татарстан Республикасы... Хезмәт инспекциясенә, ... ук суд һәм прокуратура орг... рына мөрәҗәгать итә ала.

Өстәмә килешүләрнең кө... артып торуы районда “... хезмәт хакына каршы җә... релгән көрәшнең нәтиҗәл... турында сөйли. Ә дәгъв... ның булмавы сайланган ю... дөрес икәнлеген тагы бе... раслый.

Светлана ИГНА...

## МӘГЪЛҮМАТ...

**“Соры” хезмәт хакы... Сезнең “больничн... отпускагыз, пенсия... не урлыйлармы? Ра... башкарма комитеты... “кайнар линия”сенә ... тыратыгыз – 2-06-69...**

СПОРТ

## СЕЗОННЫҢ СОҢГЫ БӘЙГЕЛӘРЕ

**Шул көннәрдә районда шахмат һәм шашка сезоны тәгәлләнде.**

Сезонның соңгы рәсми турниры исә Кубок өчен ярышлар булды. Быел анда, гадәттәгечә, уналты кеше көч сынашты. Кубокны икенче ел рәттән Сергей Анисимов яулады. II урында – Иван Прокопьев.

Шәһәрнең шашка-шахмат клубы Җиңү бәйрәменә дә традицион турнир уздырды. Шахмат бәйгесендә җиңүче исеменә Сергей Анисимов лаек булды. Григорий Ермолаев һәм Владислав Герасимов II–III урыннарны бүлештеләр. Шул ук көнне узган шашка ярышларында Олег Павлов җиңү яулады. Сергей Зайцев һәм Рифкать Әюпов II-III урыннарны алдылар.

## НУРЛАТЛЫЛАР ОСТАРАК БУЛДЫ

**Шәһәрнең “АТП” һәм “Факел” командалары Аксубай районының Иске Тимошкино авылында сугышчы-интернационалист Сергей Еграшкин истәлегенә үткәрелгән турнирда катнаштылар.**

Нәтиҗәдә, “Факел” футболчылары финалда хуҗаларның “Аксу” командасын тар-мар итеп, турнирның җиңүчесе исемен яуладылар. Өченче урынны автотранспортчылар алды. Моннан тыш, турнирның иң яхшы уенчысы дип “Факел”дан Иван Егоров танылды. АТПдан Роман Водолевский – иң яхшы капкачы, “Факел”дан Илдар Әбделвәлиев иң яхшы һөҗүмче призларына ия булдылар. Турнирда җиде команда катнашты.

Илназ МӨБАРӘКШИН


Ассортимен...
КИРПЕЧ, ГАЗОБЕТОН (ТЕПЛОН, УНИБЛОК),ҖИЛЕМ.
Т. 8-927-440-44-99

Магазин «Ковры»
Постоянные скидки 10%
на КОВРЫ, ПАЛАСЫ, ДОРОЖ...
Г. Нурлат, ул. Гиматдинова, 79. Т. 2-09-89.
ООО «ЛИДЭР»

КОЕЛАР БОРАУЛАУ.
РАЙОН БУЕНЧА КОЕ БОЖ...ЛАРЫН КИТЕРЕП БИРУ... ТҮЛӘҮСЕЗ.
Т. 8-9274-233-978.

КОЕЛАР БОРАУЛАУ.
Ямобур хезмәтләре,
төрле диаметрдагы кое бoҗралары
Т. 8-927-249-25-64.

Дети - наше будущее
* Прием детского специалиста в области офтальмологии
* Исследование зрения на компьютерном оборудовании
* Решение проблем при косоглазии, амблиопии, близорукости у детей
Салон «ДОКТОР ОПТИКА»
г. Нурлат, ул. Советская, 120,
т.: 2-17-88, 8-927-427-79-27,
ул. Гиматдинова, 81,
т.: 2-91-99, 8-937-610-69-30,
Лиц. №16-01-000675 от 13.12.2007г., выд. Фед.службой по надзору в сфере здравоохранения и соц.развития.
Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста.

БЛОКИ
СТЕНОВЫЕ
400х200х200 – 40 руб.
400х200х120 – 32 руб.
Используются для строительства домов, бань, сараев, гаражей.
Доставка от 1080 шт. по г.Нурлат и Нурлатскому району бесплатно.
8-902-337-19-37, 8-848-250-01-70.


реклама

ТЕПЛИЦЫ ОТ ЗАВОДА, ЛЮБЫХ РАЗМЕРО...
Т. 8-929-722-29-89...

«МИР КРОВЛИ И ФАСАДА»
Профнастил, м/черепица, сайдинг всех видов, гл.лист, крепеж, утеплители, пленки. Низкие цены. Кредит АО «ОТП Банк», АО «Альфа-Банк». Доборные элементы. Кровельные работы. Ул. Нурлатская, 15. Т. 8-927-671-84-84.

ВСЕ ДЛЯ БАНИ вагонка, дв...
Полы, элементы лестниц
Печи, дымоходы, камни и ...
г.Чистополь. Т. 8-927412-86...

ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА ЛИДЕР
Жалюзи 700 руб.
Теплые откосы
Отделка уличных откосов
Двери металлические, межкомнатные
Натяжные потолки (Германия) 320 руб.
KBE


НОВЫЕ ЦЕНЫ
СКИДКИ БОЛЬШЕ НЕ НУЖНЫ
Москитные сетки в подарок
Подробности по т.: 8-927-246-52-50 (84345) 9-27-95
Гарантия 5 лет М-н «Акватерм», 2 этаж
Кредит предоставлен АО «ОТП БАНК» Реклама

УТЕПЛЕНИЕ СТЕН И ПОТОЛКОВ ПЕНОИЗОЛОМ.
10 лет опыта работы.
8-937-600-33-02.

ТЕЛӘСӘ НИНДИ КАТЛАУЛЫЛЫКТАГЫ ТАРТТЫРЫЛМА ТҮШӘМНӘР.
8-9600-33-77-55.

НАРКОЛОГИЯ
ИП ЕРЕМИН АНДРЕЙ ВИКТОРОВИЧ
Т. 8-937-409-28-07.
Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста.
Лиц. Г 855897, рег. 192 от 05.07.2012 г., выд. Лицензионной палатой Самарской области.

УСЛУГИ АВТО-КРАНА
25 ТН, ВЫЛЕТ СТРЕЛЫ 21 М.
8-927-444-70-80.




Доступные ЗАЙМЫ.
Выгодные условия в Нурлате.
8-927-455-66-17, ул. Советская, д. 113а.
ООО «Импульс-АС».
ОГРН 1146320005325.
http://импульс-ас.рф.

ПРИЦЕПЫ.
г.Саранск, г. Курган.
8-927-736-59-42.

Открылся МЕБЕЛЬНЫЙ САЛОН
Центральный рынок (около автовокзала), бутик №11.
Заказы принимаются по индивидуальным размерам.
ТРЕБУЮТСЯ продавцы с опытом работы.
8-987-423-09-01.

«ЧИСТОПОЛЬ АВТО»
ОФИЦИАЛЬНЫЙ ДИЛЕР « LADA »
ТОЛЬКО с 12 мая по 31 мая 2015 года реализует автомобили LADA по акциям.
Общая сумма скидок на все автомобили LADA составляет от 70 000 руб. до 100 000 рублей.
Принимаем заказы на поставку автомобилей LADA, РЕНО, ШЕВРОЛЕ-НИВА, по рекомендованным ценам заводов изготовителей.
РТ, г. Чистополь ул. Валиева д.7а.
Работаем с 8-00 до 18-00, в субботу и воскресенье с 8-00 до 13-00.
Подробности акции по тел.8(84342) 4-15-55.
Организатор акции: ООО «Чистополь-Авто».
Реклама

Студия красоты «ОБРАЗ»
предлагает услуги:
- парикмахера,
- свадебный, вечерний макияж,
- татуаж бровей, век, губ,
- депиляция воском,
- ногтевой сервис.
Ул. Пушкина, 45.
2-31-40, 8-927-248-42-78, 8-927-419-36-36.

ООО «МИР КРОВЛИ»
реализует
ПРОФНАСТИЛ С9, С20, С21, НС44, Н60, Н75 (оцинкованный и ...шенный), длина до 12 метров, металлочерепицу, металлосай..., металлоштакетник, профильную трубу, гладкий лист, добор... элементы. Утеплитель. Парогидроизоляция. Поликарбонат. Те...
Доставка по городу бесплатно.
Гарантия на всю продукцию.
Т.: 8-927-826-53-32, 8-937-273-87-15, 8(84235) 2-75-35, 2-72-25.
E-mail: mir-krovli73@bk.ru

# КОТЛАУЛАР. БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Кадерле кешебез **Рушания Нургата кызы Әхмәтвәлиевaны** юбилее белән тәбрик итәбез.

Котлы булсын, апа,
туган көнең,
Нурлар чәчсен
һәрчак йөзләрең,
Сәламәтлек, куаныч һәм
шатлык белән
Үтсен синең алгы көннәрең.
Сабыр да син, гади,
кешелекле,
Кылган эшең бары изгелек,
Тынычлыкта үтсен синең
көннәр,
Бәхетләрең булсын гомерлек.

**Иң изге теләкләр белән Хәлил, Индира, Рәфис, Эльмира, Айнур, Эльвина, Айсылу.**

**Чишмә авылында** яшәүче яраткан тормыш иптәшем, әтием **Наил Шакир улы Кәлимуллинны** юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз.

Аңа исәнлек, чиксез бәхет, куанычлар, гаилә иминлеге, кайгы-хәсрәтсез көннәр телибез. Авырлыклар алдында бирешмәвеңә, зирәк, акыллы булуыңа сокланабыз, эш-гамәлләрең, киңәшләрең белән һәрчак янәшәбездә булуыңа сөенәбез.

Син булганда без бәхетле,
Синең белән якты көнебез.
Безнең белән син дә
бәхетле бул,
Сиңа озын-озак гомер
телибез.
Шатлык-куанычлар,
сәламәтлек
Ташламасын сине гомергә,
Йортыбызны җылытучы учак,
Нур сибүче кояш син безгә!

**Сине яратып тормыш иптәшең Гөлия, кызың Гөлинә.**

**Чишмәдә** яшәүче киявебез, баҗам, җизнәбез **Наил Шакир улы Кәлимуллинны** гомер бәйрәме белән котлыйбыз.

Алдагы көнендә кызыбыз Гөлия белән бергә озын-озак гомер итүләрен, саулык, гаилә тынычлыгы, газиз балагыз Гөлинәнең кадерле әтисе булуыңны, оныклар куанычы телибез.

Ачык йөзле, киң күңелле,
Син ярдәмчел дуска, туганга,
Яратабыз, хөрмәтлибез
Акыллы һәм тырыш булганга.
Гаилә нигезе нык син
булганга гына,
Рәхмәт синең төпле сүзеңә.
Безгә булган изгелегең,
игътибарың
Савап булып кайтсын үзеңә!

**Сине хөрмәт итеп бабаң Хафиз, әбиең Роза, балдызың Ләйсән, кайнең Илназ гаиләләре.**

Сөекле тормыш иптәшем, әниебез, әбиебез **Рива Галим кызы Газизованы** туган көне белән ихлас котлыйбыз!

Сабырлыгың, күркәм
холкың белән
Дөньябызны безнең
бизәдең.
Һәммәбезне сөеп,
акыл белән
Тигезләдең яшәү бизмәнен.
Олы җанлы, мәрхәмәтле
булдың,
Кичерә белдең борчу
китерсәк.
Бар гамәлең, догаң
безнең өчен,
Кадерлебез, сиңа
зур рәхмәт!

**Тормыш иптәше, балалары, килене, киявләре, оныклары.**

**Киекле авылында** яшәүче кадерлебез **Роза Нуретдин кызы Билалованы** чын күңелдән олы юбилее белән котлыйбыз! Уңганлыгы, киң холкы, якты йөзе белән якыннарын сөендерә, һәммәбезгә күңел җылысын өләшә. Рәхмәт аңа! Чын күңелдән абыебыз белән тигез гомер итеп, балаларының рәхәтен күреп кадер-хөрмәттә яшәргә язсын дип телибез.

**Роза, Алмаз һәм балалар.**

Кадерле туганыбыз **Лилия Фаикъ кызы Әбҗәлимованы** юбилее белән ихлас күңелебездән тәбрик итәбез!

Якты кояш һәрчак юлдаш булсын,
Шатлык тоеп типсен йөрәгең,
Кайгы-хәсрәт сине урап үтсен,
Кабул булсын һәрбер теләгебез.
Бәхетле һәм озын гомерле бул,
Пар канатың булсын янәшә,
Балаңның игелеген күреп,
Гел сөенеп, көлеп син яшә.

**Әбиең, апаң, балалары.**

**Мәрьям Якуб кызы Курамшинаны** юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз!

Аңа нык исәнлек, якты, тыныч көннәр, бәхет телибез. Балалары, оныклары, күпсанлы дуслары арасында бүгенгедәй ихтирамлы булып, тормыш иптәше Мансур белән озын, тигез гомер итәргә язсын!

**Иң изге теләкләр белән "Изобилие" кибетчеләре.**

Хөрмәтле **Һавил Сабир улы Рәхимовны** олуг юбилее - 90 яшь тулган көне белән чын күңелдән тәбриклибез!



Дөньядагы һәрбер
яхшылыктан
Өлеш чыксын сезгә мул гына.
Без телибез сезгә ак
бәхетләр,
Шатлыкларга илткән юл гына.
Бәйрәмнәрнең матур хатирәсе
Күңелләрдә калсын уелып.
Тәбриклибез сезне
чын күңелдән,
Барыбыз да бергә җыелып.

**Финанс-бюджет палатасы коллективы.**

**Биккол авылында** яшәүче кадерле әтиебез **Дамир Бәхтегәрәй улы Вафинны** олы юбилее – 80 яшьлеге белән котлыйбыз!

Әтиебез - таләпчән, иҗади,
Гадел, үтә йомшак күңелле,
Зирәк тә ул, көчле дә ул
безнең,
Изгелектә аның һәр көне.
Тырыш кеше ташка
кадак кага,
Бәхетен тапкан безнең
әти дә.
Кешелекле булган өчен аңа
Күпләр килә рәхмәт әйтергә.
Әти барыбызга бик кадерле,
Әниебезгә дә ул нык терәк.
Бу дөньяда әти күк кешеләр
Булсын иде әле күбрәк!

Әтиебезгә нык сәламәтлек, күңел тынычлыгы, әниебез белән тигезлектә тыныч озын гомер итүләрен, якыннарының игелекләрен күреп, бәхетләренә сөенеп яшәүләрен телибез.

**Әниебез, 2 улың, 3 кызың, кияүләрең, киленнәрең, 10 оныгың һәм онықчыгың Руслан.**

## НЕДВИЖИМОСТЬ

*дом или обмен. Т. 8-919-684-40-03.
*дом, 800000 руб. Т. 8-937585-54-23.
*дом, ул. Куйбышева. Т. 8-929-72-30-066.
*2-комнатная квартира, 44 кв.м, 1 этаж. Т. 8-937-28-76-084.
*2-комнатная квартира, пер. Заводской. Т. 8-937-777-25-47.
*дом, ул. Советская, 17. Т. 8-9272-43-65-08.
*3-комнатная квартира, ул. Шашина. Т. 8-927-474-46-16.
*2-комнатная квартира. Т. 8-927-462-47-08.
*1-комнатная малосемейка, мкр. Яшлек, 500000. Т.: 8-927-245-66-78, 8-927-403-91-42.
*дом по ул. Мугинова. Т. 8-987-421-39-97.
*магазин на продуктовом рынке. Т. 8-927-049-26-51.
***дом,** ж/д, все есть, 1800000 руб.; **недострой,** ул. Ипподромная, 1100000 руб.; **2-комнатная квартира,** 950000 руб.; **коттедж**, ул. Тукая, 3,6 млн. руб.; **коммерческая недвижимость.** Т. 8-929-727-12-82 (Ксения).
*2-комнатная квартира, с ремонтом, ул. Кариева, цена 1450000 руб. Т. 8-927-419-99-12.
*1-комнатная квартира, ул. Советская, 187. Т. 8-937-036-64-96.
*3-комнатная квартира, 2 этаж, мкр. Яшлек. Т. 8-917-880-52-50.
*недостроенный дом. Т. 8-987-413-96-70.
*элитный коттедж, ул. Юданова, подробности при осмотре, 6,9 млн. руб., торг. Т. 8-937-610-48-70.
*элитный коттедж, ул. Фахрутдинова, 6,7 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*коттедж, с. Тюрнясево, новый, 180 кв.м. Т. 8-937-610-48-70.
*3-комнатная квартира, ул. Нурлатская, 3 этаж, 63 кв.м, 1380000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*нежилое помещение, д. Нижний Нурлат, 180 кв.м. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, д. Бурметьево, 70 кв.м, 700 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, ул. Курмышская, 32, 1850000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*3-комнатная квартира, мкр. Яшлек, 5 этаж, 1250000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, 1 этаж, центр, 950 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*3-комнатная квартира, ул. Заводская, 70 кв.м, 1 этаж, 950 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*коттедж новый, 4 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, новая, 51 кв.м, индивидуальное отопление, 1350000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*комната в общежитии, 250000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, мансарда, 53 кв.м, 700000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, баня, гараж, 2,5 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*1-комнатная квартира, новая, 1 этаж, 40 кв.м, 850000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, с/з, 1 этаж, 720000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, ул. Ленинградская, д. 9, 51 кв.м, 3 этаж, 1,3 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, ул. Садовая, 5 этаж, 50 кв.м, или обменивается на 1-комнатную с доплатой. Т. 8-937-610-48-70.
*дача («Здоровье»), с документами. Т. 8-927-422-89-57.
*3-комнатная квартира, центр. Т. 8-937-580-20-79.
*2-комнатная квартира, центр, 2 этаж. Т. 8-927-450-16-85.
*дом с участком, все подведено, не подключено. Т. 8-927-248-38-03.
*3-комнатная квартира, 70 кв.м, ул. Халикова. Т. 8-937-580-28-39.
*1-комнатная квартира в Альметьевске. Т. 8-917-909-34-48.
*дом, ул. Михеева; 2-комнатная квартира, ул. Сайдашева. Т. 8-937-77-40-132.
*дом на вывоз или дрова. Т. 8-927-246-79-42.
*дом в Биляр-Озеро. Т. 8-937-288-32-63.
*дом в Курманаево. Т. 8-937-616-45-84.
***1-комнатная квартира**, ул. Гиматдинова, 630000 руб.; **2-этажный дом,** ул. Тукая; дом, ул. Фахрутдинова; **недострой**, ул. Дальняя, 1, 950000 руб.; недострой, ул. Куйбышева, 950000 руб.; **земельный участок** (№16-16-03/001/2008-451). Т. 8-937-600-47-73 (Алсу).

## АВТОТРАНСПОРТ

*срочно «МАЗ 53366-040», 2000 г/в, цена договорная. Т. 8-927-243-28-74.
*«МТЗ-82.1», 2012 г/в, с погрузчиком + коммунальный отвал, щетка + прицепной саг двигатель «Т-40». Все в отличном состоянии. Т. 8-937-987-96-95.
*«ВАЗ-2115», 2006 г/в. Т. 8-929-728-70-71.
*«Лада Калина», универсал, 2012 г/в. Т. 8-927-403-48-57.
*«Рено Дастер», 2014 г/в, цвет золотисто-коричневый. Т. 8-937-100-48-38.
*трактор «МТЗ-50» с куном. Т. 8-927-698-75-16.
*«ГАЗель» бортовая (2003 г/в) или обменивается на л/а. Т. 8-987-413-96-70.
*«МАЗ», самосвал, 2012 г/в, 20 тонн, евро-2. Т. 8-9872-86-70-01.
*«ВАЗ-2112», 2007 г/в, с ГУРом. Т. 8-929-721-60-60.
*«Лифан Солано», черный, 2011 г/в, 75000 км, 260000 руб., срочно. Т. 8-927-671-72-20.
*«Дэу Нексия», 2011 г/в, хорошее состояние, один хозяин. Т.: 8-927-438-99-53, 8-927-423-76-74.
*«Ниссан Кашкай», 2010 г/в, небитый, в хорошем состоянии. Т. 8-927-246-79-42.
*«Лада Гранта», лифбек, пробег 1200, сентябрь 2014 г/в. Т. 8-937-774-56-11.
*«ВАЗ-21093», инжектор, 2004 г/в, темно-зеленый, состояние хорошее. Т.: 8-927-433-50-42, 8-927-441-86-56.

## ДРУГОЕ

*ШИКӘР КОМЫ-2250, ОН-970, «Юмарт» кибете. Т. 8-927-445-68-55.
*куры-молодки, бройлеры, несушки, утки, гуси. Т. 8-927-483-06-10. 8-917-293-27-47.
*Костер, люцерна орлыклары. Т. 8-927-470-39-02.
*ПГС, песок, кольца разного диаметра. Т. 8-937-28-62-082.
*ПГС, песок, буткамень. Т. 8-927-247-27-37.
*доски (осина, сосна), брусья. Доставка. Т. 8-937-003-84-85.
*бычки (молодняк) от 2 до 5 месяцев. Т. 8-927-870-58-98.
*телята молодняк. Т. 8-927-987-87-63.
*песок, ПГС, щебень, бут, цемент, кирпич, чернозем, перегной. Т. 8-927-247-94-76.
*ПГС, ОПГС, песок от 3 тон. Т. 8-927-244-84-71.
*ПГС, песок. Т. 8-927-404-66-44, 8-927-244-11-33.
*семена костер, люцерны. Т. 8-927-470-39-02.
*окна, б/у, пластиковые, 3 штуки. Т. 8-927-033-76-75.
*чернозем, перегной. Т. 8-927-463-63-17.
***доски осина, сосна, брусья. Доставка. Т. 8-937-003-84-85.**
*утки, гуси, молодки, бройлеры. Доставка. Т.: 8-937-286-57-23, 8-937-621-81-57.
*дрова. Т. 8-927-423-62-12.
*рамки для ульев. Т. 8-937-281-68-53
*диван угловой с креслом. Т. 8-927-247-07-22.
*корова, 4 отела, красно-пестрая. Т. 8-917-221-70-64.
*дрова сухие. Т. 8-987-213-32-95.
*коляска зима-лето, 3500 руб. Т. 8-937-572-44-04.
*емкость на 3,6 куб. Т. 8-987-413-96-70.
*телята от 1 месяца до 1 года мясной, мясо-молочной, симментальской пород, недорого. Доставка бесплатно. Т.: 8-937-343-80-22, 8-909-345-99-77.
*дрова. Т. 8-937-003-27-27.
*овцы с ягнятами, КРС на мясо. Т. 8-937-792-79-92.
*велосипед взрослый и детский 4-колесный, недорого. Т.: 2-14-45, 8-927-475-97-97.
*козье молоко. Т. 8-927-443-76-66.
*бычки симментальской, мясной пород весом 170-220 кг; ячмень 105 т.; пчелосемьи 50 шт. на выбор. Т. 8-917-882-51-39.
*организация распродает двигатель, КПП для «КамАЗа», «ГАЗа»; а/м «ЗИЛ» («бычок»), 2007 г/в. Т. 8-927-207-61-92.
*глина, песок, ПГС, чернозем. Т. 8-927-466-66-83.
*гусята. Т. 8-927-409-54-03.
*ПГС. Т. 8-927-414-61-34.
*дрова. Т. 8-987-181-45-44.
*ЖБИ плиты перекрытия, стеновые панели, пенобетон-панели, б/у, срочно, цена договорная. Т. 8-927-413-48-30.
*ПГС. Т. 8-927-617-11-21.
*корова. Т. 8-937-297-30-70.
*пчелы. Т. 2-05-09.
*керамзит-керамблоки. Доставка. Т. 8-927-247-85-89.
*швеллер 16 см, советский, ванна чугунная (150 см), матрац двуспальный, 160х180 (Италия). Т.: 2-26-80, 8-917-913-64-93.
*детский диван, б/у. Т. 8-937-292-70-77.
*сруб бани, новый; дрова, перегной, чернозем, песок, бут. Т. 8-927-413-05-92.
*ульи, пчелы. Т. 8-927-423-56-08.
*пчелосемьи, дешево. Т. 8-927-245-28-06.

## РАЗНОЕ

***Йомшак җиһаз тарттыру, ремонтлау. Т. 8-937-570-60-21.**
***Йөк күчерү, «ГАЗель». Т. 8-937-570-60-21.**
*Электрик хезмәтләре. Т. 8-987-418-35-00.
*ремонт холодильников. Т. 8-927-419-56-48.
*натяжные потолки. Т. 8-927-036-53-65. (Алексей)
*вспашка земли. Т. 8-927-481-29-70.
*кроем кровлю, обшиваем дома и другие строительно-ремонтные работы. Т. 8-927-422-26-33.
*перегной, песок, ПГС. 8-927-424-02-83.
*ремонт стиральных машин. Т. 8-927-468-16-31.
*ремонт холодильников. Т. 8-927-247-93-50.
*услуги электрика. Т. 8-937-614-70-15.
*бычки (молодняк). Т. 8-927-870-49-62.
*помощь компьютеру. Т. 8-909-308-22-56.
*коза. Т. 2-17-93.
*пчелосемьи. Т.: 8-927-466-12-03, 2-84-98.
*пчелосемьи. Т. 3-92-49.
*готовый бизнес (парикмахерская). Т. 8-927-402-45-00.
*штукатурка, вагонка, кровля, бетонные работы. Т. 8-917-865-30-35.
*монтаж, демонтаж отопления, воды, канализации, любой сложности. Качественно, быстро. Выезд. Т.: 8-927-037-10-26, 8-987-400-82-71.
*грузоперевозки, «ГАЗель», 4 м, 16 куб. Т. 8-927-247-12-61.
*грузоперевозки, «ГАЗель». Т. 8-987-413-96-70.
*ремонт квартир. Т. 8-927-419-71-51.
*подготовлю будущего первоклассника к школе. Т. 8-9270-35-72-68.
*ищу работу сиделки, охранника. Т. 8-927-421-18-10.

## СДАЮТСЯ

*квартира посуточно. Т. 8-927-406-11-06.
*квартира посуточно, командировочным. Т. 8-927-456-05-69.
*квартира. Т. 8-927-474-46-16.
*2-комнатная квартира, г. Казань, ул. Хади Такташ,119, на 4 этаже, долгосрочно. Т. 8-937-524-27-75.
*2-комнатная квартира. Т. 8-927-443-66-84.
*1-комнатная квартира по ул. Куйбышева. Т.: 8-927-046-29-08, 8-937-600-49-53.
*2-комнатная квартира. Т. 8-927-247-00-80.

## КУПЛЮ

***Алгы приводлы «ВАЗ»лар, чит ил машиналары. Кыйммәткә. Т. 8-927-456-00-07.**
*КЫЙММӘТКӘ АВТО САТЫП АЛАМ. Т. 8-937-588-36-46.
*Мөгезле эре терлек, эре терлек тиреләре. Кыйммәткә. Т. 8-927-412-29-99.
*Мөгезле эре терлек, эре терлек тиреләре. Кыйммәткә. Т. 8-927-443-05-43.
*пух-перо утиное, гусиное. Старые подушки, перины. Т. 8-987-062-55-26.
*земельные паи (бывшего колхоза им. Хафизова). Т. 8-927-402-01-70.

## ПОТЕРИ

*утерянную 5 мая медаль «70 лет Победы в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.» прошу вернуть за вознаграждение. Ул. Циолковского, 13-33.
*утерянный паспорт самоходной машины ТС №360380, выданный на имя Раиса Ризалетдиновича Самигулова, считать недействительным.

## ТРЕБУЕТСЯ

*грузчики. Т. 8-927-445-68-55.
*маникюрист. Т. 8-927-421-80-33.
*штукатуры-маляры. Т.: 8-927-442-63-23, 8-927-442-66-12.
*ЗАО «Нурлатский элеватор» медицинский работник. Т. 8(84345) 2-00-28.
*охранник. Т.: 8(84345) 2-78-66, 8-937-770-11-72 (звонить с 8.00 до 17.00).
*охранники (не имеющих удостоверения охранника направляем на срочное обучение). Т. 8-937-292-60-65.
*слесари в ТСЖ. Т. 2-69-09.

## СНИМУ

*семья квартиру. Своевременную оплату и порядок гарантируем. Т. 8-927-043-86-54.

12+ **"ТНТ-Нурлат" тәкъдим итә**

**18 МАЙ**
Музыкаль тапшыру, чуваш телендә.

**20 МАЙ**
"Нурлат хәбәрләре",
"Татнефть" хәбәрләре.

**22 МАЙ**
**"Нурлат хәбәрләре".**
**"Сиңа дигән җырым"**, музыкаль тапшыру

Программалар **19** сәгатьтә башлана. **19, 21 майда, 23 майда** иртәнге **7дә** кабатлап күрсәтелә.

**Магазин «Аладдин»**
Матрасы, одеяла, подушки, пледы, спальные комплекты, покрывала, шарфы, платки, тюбетейки, намазлык, полотенца, салфетки, наперники, наволочки, коврики для ванн и прихожих. Клеенки и скатерти. Доступные цены. Работаем за наличный и безналичный расчет.
**г. Нурлат, ул. Гиматдинова, 79. Т.: 8(84345) 2-09-89, 8-967-462-10-03.**

**АШЫГЫЧ! НУРЛАТ ГАИЛӘСЕНӘ ЯРДӘМ КИРӘК!**

**Нурлаттан Әбдрахмановлар гаиләсе 2011 елгы уллары Булатны дәвалауга средстволар җыярга ярдәм сорап битараф булмаган якташларга мөрәҗәгать итә. Диагнозы - баш мие үсешендә тайпылыш. Саклык банкы картасы номеры - 4276620013356211, карта 2016 елның февраленә кадәр гамәлдә.**

